**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
2025 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Мәсгүт авыл җирлегендә,
Яхшы-Бай торак пунктында
үзара салым кертү турында

**25 октябрь 2024 ел.** **№ 4**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлеге Мәсгүт торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгүт авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән карата 500 сум күләмендә, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләр, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

-Су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Татарстан Республикасы Азнакай МР Якшыбай торак пунктында су агызу өчен материаллар һәм җайланмалар сатып алу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында, Мәсгүт авыл җирлегенең Яхшы-Бай торак пунктында мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Мәсгүт авыл җирлеге
башлыгы:

И.А.Вильданов